**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2025 **Чирмешән авылы** **№ 384**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Чирмешән муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны җайга салу һәм алар белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законына таянып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү тәртибе (1 нче кушымта);

- Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составы (2 нче кушымта);

- Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү комиссиясе турында нигезләмә (3 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетын Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында җайга салына торган тарифлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 16 октябрендәге 487 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Г. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.12.2025 № 384карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү тәртибе**

## I. Субсидияләр бирү тәртибен эшләү нигезләре һәм максатлары

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы һәм Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге тәртип Чирмешән муниципаль районы бюджеты акчаларыннан, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидия исәбеннән төзелгән акчалардан агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив-хокукый актында билгеләнгән күләмдә юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 ел, № 44-ФЗ Федераль закон нигезендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең конкурент ысуллары белән сайлап алынган индивидуаль эшкуарларга субсидия бирү процедурасын һәм шартларын билгели, аларга җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында Чирмешән муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында (Алга таба – Ташучы, Субсидияләр).

1.3. Субсидиянең максаты булып бюджет йөкләмәләре лимитларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанслау объектларында каралган акчалар чикләрендә түләүсез һәм кире кайтарылмас нигездә пассажирлар йөртү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау тора.

1.4. Субсидияләр бирү нәтиҗәсе булып Чирмешән муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның субсидия алучы хезмәт күрсәтә торган муниципаль маршрутларында йөрү бәясен арттырмау тора.

## II. Субсидия бирү хокукына ия юридик затлар һәм (яисә) индивидуаль эшкуарлар категорияләре

2.1. Субсидияләр бирүгә түбәндәге категория юридик затлар һәм (яисә) индивидуаль эшкуарлар дәгъва кылырга хокуклы:

- Россия Федерациясе салым органында тиешенчә теркәлгәннәр;
- 8 (сигез) кешедән артык пассажирлар йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләре булганнар;
- сайлап алуда катнашучылар чит ил юридик затлары булырга тиеш түгел, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булган чит ил юридик затлары (алга таба - офшор компанияләре), шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан артыграк булган россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса). Россия юридик затлары капиталында офшор компанияләренең катнашу өлешен исәпләгәндә офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган гавами акционер җәмгыятьләр капиталында турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән), шулай ук мондый офшор компанияләрнең күрсәтелгән гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затлары капиталында читләтеп катнашуы исәпкә алынмый.

## III. Субсидияләр бирү шартлары

3.1. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче числосына түбәндәге критерийларга туры килергә тиешле юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга-товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә (алга таба оешмалар) бирелә:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутларда гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүгә бәйле хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр

сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән муниципаль контрактның булуы;

- Чирмешән муниципаль районының даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрут челтәре буенча пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү;

- даими йөрүче маршрут буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесе нигезендә пассажирлар йөртү буенча хезмәтләр күрсәтү;

- ташучының документлар белән расланган төшеп калучы керемнәр барлыкка килүе;

- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штраф пенялары, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы;

- Чирмешән муниципаль районы бюджетына бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычның һәм бюджет алдында срогы чыккан бүтән бурыч булмавы;

- субсидияләр алучылар-юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидияләр алучылар-шәхси эшмәкәрләр шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлекләрен туктатырга тиеш түгел;

- сайлап алуда катнашучылар чит ил юридик затлары булырга тиеш түгел, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булган чит ил юридик затлары (алга таба - офшор компанияләре), шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан артыграк булган россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса). Россия юридик затлары капиталында офшор компанияләренең катнашу өлешен исәпләгәндә офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган гавами акционер җәмгыятьләр капиталында турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән), шулай ук мондый офшор компанияләрнең күрсәтелгән гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затлары капиталында читләтеп катнашуы исәпкә алынмый;

- Субсидияләр алучылар әлеге Тәртип нигезендә субсидияләр бирү планлаштырылган Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан акчаларны әлеге Тәртипнең 1.1 пунктчаларында күрсәтелгән максатларга башка муниципаль хокукый актлар нигезендә алырга тиеш түгел.

3.2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты Алучы белән субсидия бирү турында Килешү (алга таба - Килешү)

төзи.

3.3. Бюджет акчаларын баш бүлүче һәм субсидия алучы, шулай ук башка оешма (кирәк булганда) арасында килешү, килешүгә Өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда), дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп төзелә торган килешүләрдән тыш, Россия Федерациясе субъектының финанс органы (муниципаль берәмлекнең финанс органы) тарафыннан тиешле субсидияләр өчен билгеләнгән үрнәк рәвешләр нигезендә төзү.

3.4. Бюджет акчаларын баш бүлүчегә килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган бюджет йөкләмәләренең элегрәк җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турындагы яисә яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә килешүне өзү турындагы шартларны килешүгә кертү.

## IV. Субсидияләр бирү тәртибе

4.1. Субсидия алу өчен ташучы ай саен, хисап айыннан соң килә торган айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, ә декабрьдә 20 числосына кадәр комиссия каравына түбәндәге документларны тапшыра:

- субсидияләр бирү турында гариза;
- ташуларны гамәлгә ашырудан төшеп калучы керемнәрнең барлыкка килүен раслый торган исәп-хисапны әлеге Тәртиптә билгеләнгән форма буенча (Тәртипкә 1 нче кушымта).

Хезмәт күрсәтүгә һәм Субсидия алуга ташучы белән муниципаль контракт төзелгәннән соң, Ташучы түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

- Чирмешән муниципаль районында гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж йөртүгә максималь чик тарифлар билгеләү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары;
- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча контракт төзү датасына үтәлмәгән бурычның булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетына башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычның, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча бүтән срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычның булмавы турында предприятие җитәкчесе имзалаган гарантия хаты;
- предприятие җитәкчесе тарафыннан имзаланган, предприятие үзгәртеп оештыру (предприятиегә башка юридик затны кушу рәвешендәге үзгәртеп корудан тыш), бетерү процессында булмавын раслый торган гарантияле хат,

аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, предприятие эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

- предприятие җитәкчесе имзалаган гарантия хаты, ул предприятиенең чит ил юридик заты булмавын, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын тәкъдим итүче һәм (яисә) финанс операцияләре үткәргәндә (офшор зоналары) мәгълүматны ачу һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан артык булган Россия юридик заты булмавын раслый;

- предприятие җитәкчесе тарафыннан имзаланган, әлеге Тәртипнең 1.1 пунктларында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә предприятие Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан акча алмавын раслаучы гарантия хаты.

Предприятие тарафыннан тапшырыла торган документлар (документларның күчермәләре):

- предприятие җитәкчесе яисә башка вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган (гамәлдәге законнар нигезендә вәкаләтләрне раслый торган документларны кушымта итеп);

- тегелгән, номерланган һәм печать белән беркетелгән;

- техник чаралар кулланып, пөхтә итеп, чистартуларсыз, төзәтүләрсез, ялгышларсыз, билгесез кыскартуларсыз һәм ике төрле аңлату мөмкинлеге бирә торган формулировкаларсыз башкарылган.

4.2. Ташучы тапшырган документларны карау нәтиҗәләре буенча субсидия бирү документларын карау комиссиясе 10 эш көне эчендә төшеп кала торган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү яисә дәлилләнгән рәвештә баш тарту турында, аны беркетмә итеп рәсмиләштереп, карар кабул итә.

4.3. Килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы) ;

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

- ташучының Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты раслаган тарифның иң чик дәрәҗәсеннән түбәнрәк (алга таба-тарифның иң чик дәрәҗәсе) тарифлар куллануы

4.4. Кисәтүләр булган очракта документлар кисәтүләрне бетерү өчен ташучыга кайтарыла, шул ук вакытта документларны кире кайтару сәбәпләре язма рәвештә чагылдырыла. Кисәтүләр булган очракта, ташучыга аларны төзәтү өчен бирелгән гомуми срок документлар алынган көннән алып 3 календарь көннән артмаска тиеш.

4.5. Субсидия Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан төшеп калучы керемнәрне каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 (ун) эш көне дәвамында Ташучы счетына күчерелә.

4.6. Бирелә торган субсидиянең күләме билгеләнгән тәртиптә кимегән очракта (бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Чирмешән муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанслау күләмнәре җитәрлек булмаган очракта) киметелергә мөмкин.

4.7. Субсидия бирү пассажир ташучы тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, автотранспорт предприятиесе ябылган, үзгәртеп корылган очракларда һәм РФ законнарында каралган башка очракларда туктатылырга мөмкин.

4.8. Бирелә торган субсидия турында мәгълүматны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре, бердәм портал) Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (бердәм портал бүлегендә) урнаштыру.

## V. Төшеп калучы керемнәрне каплау суммасын исәпләү

5.1. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы алучыдан барлыкка килә торган төшеп калучы керемнәрне каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча исәп-хисап юлы белән билгеләнә:

$$С = З – Д$$

кайда:

С - субсидияләр күләме, мең сум;

З - даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларының автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27.12.2024, № 1221 номерлы карары белән расланган транспорт чарасы классына карап, 1 км араның иң чик норматив үзкыйммәтен һәм маршрут озынлыгын исәпкә алып, җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга чыгымнар;

Д - даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр мең сумнарда.

Ташучының керемнәре составында керемнәрнең түбәндәге төрләре исәпкә алына:

- муниципаль ташулар вакытында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга

бер тапкыр бирелә торган билетлар сатудан кергән табыш;

- ташучының гражданнарның ташламалы категорияләрен социаль йөртү билетлары буенча йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан бирелә торган чыгымнарын компенсацияләү суммалары.

Шул ук вакытта ташучының керемнәре транспорт чарасының тулу күрсәткеченнән чыгып, кимендә 25% ка исәпләнә.

## VI. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

6.1. Ташучылар субсидияләр рәвешендә алынган бюджет акчаларын тапшырылган документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча, шулай ук башка контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә төшеп калган керемнәр суммасының фактта барлыкка килгән төшеп калган керемнәр өстеннән төшеп калган керемнәрне нигезсез күрсәтү күләмендә нигезсез булуы ачыкланган очракта кире кайтарырга тиеш.

Субсидияләрне кире кайтару Чирмешән муниципаль районы бюджеты акчаларыннан башкарыла торган компенсация түләүләрен каплауга Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелгән субсидияләр арткан очракта гамәлгә ашырыла.

6.2. Ачыкланган хокук бозулар акт белән рәсмиләштерелә, ул комиссия тарафыннан имзалана һәм субсидияләр алучы ташучыга бирелә.

6.3. Актны алган көннән алып 30 календарь көннән дә артмаган вакытта пассажир ташучы агымдагы финанс елында артык алынган акчаларны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына кайтарырга тиеш.

6.4. Кире кайтарылган субсидияләр суммалары Чирмешән муниципаль районы бюджеты керемнәренә күчерелергә тиеш.

6.5. Субсидияләр кайтарылмаса, вәкаләтле орган кире кайтарылырга тиешле бюджет акчаларын суд тәртибендә түләтү чараларын күрә.

## VII. Контроль

7.1. Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы оешмаларның субсидияләрдән файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен, шулай ук аларны бирү нәтиҗәләрен тикшерә

7.2. Субсидияләр бирү шартларын бозу йә алардан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта, субсидияләр вәкаләтле органның язма таләбе буенча субсидия алучы тарафыннан бер ай эчендә Чирмешән муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш. Әгәр субсидия билгеләнгән вакытта кире кайтарылмаса, ул гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Чирмешән муниципаль районы бюджеты кеременә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.12.2025 № 384карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе**<br>Җамалетдинов<br>Илнур Минсәгыйть улы | Чирмешән муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **Комиссия рәисе урынбасары**<br>Вильданов Муса<br>Габделхак улы<br><br>**Комиссия секретаре**<br>Шәйхетдинова Миләүшә<br>Рәшит кызы | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары<br><br>Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече |
| **Комиссия әгъзалары**<br>Җиһаншина<br>Эльвира Борындай Кызы | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Исмендеева<br>Ирина Петровна | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Кәримова<br>Лилия Шәфигулла кызы | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Мортазина Лилия<br>Габдрауф кызы | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Харисов Радик<br>Рәфхат улы | Чирмешән муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе |

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.12.2025 № 384карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү өчен дәгъвачыларның (оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның) заявкаларын карау буенча комиссиянең компетенциясен һәм эш тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының башка норматив-хокукый актларына таяна.

3. Комиссия составына һәм әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - район Башкарма комитеты) карары белән гамәлгә ашырыла.

4. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен түләүсез нигездә алып баралар.

5. Оешмаларга субсидия бирү өчен заявкалар район Башкарма комитеты тарафыннан җыела.

6. Гариза тәртипнең 4.1 пунктында күрсәтелгән документлар белән эш көннәрендә район башкарма комитетына тапшырыла.

7. Район башкарма комитеты барлык алынган документларны алга таба эшләү өчен заявка теркәлгән көннән бер көннән дә соңга калмыйча комиссиягә тапшыруны тәэмин итә.

8. Комиссия тарафыннан заявканы кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булырга мөмкин:

1) заявканың Тәртиптә каралган таләпләргә туры килмәве.

Бу чакта гаризада техник хаталар яисә төгәлсезлекләр булса һәм алар гаризаның асылын үзгәртмичә бетерелергә мөмкин һәм башка катнашучыларны тигезсез шартларга куймаса, гариза билгеләнгән таләпләргә туры килми дип таныла алмый.

Комиссия билгеләнгән тәртиптә заявканы кире кагу турындагы мәсьәләне хәл иткәндә заявканың асылын үзгәртмичә генә бетерелергә мөмкин булган техник хаталарга яисә төгәлсезлекләргә кертү предметына заявканың ачыкланган

туры килмәвен бәяләү турында карар кабул итә;

2) предприятиенең Заявка составында дөрес булмаган, белә торып ялган мәгълүмат бирү фактын ачыклау.

9. Предприятиеләрне сайлап алуга кертү өчен критерий булып заявканың тулылыгы һәм вакытында бирелүе тора.

10. Предприятиеләрне сайлап алу критерийлары тәртипнең 2.1 пункты белән билгеләнә.

11. Комиссия эше утырышта исемлек составының кимендә яртысы катнашканда хокуклы була.

Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсен комиссия секретаре алып бара, беркетмәгә комиссиянең утырышта булган барлык әгъзалары имза сала.

12. Комиссия үз эшчәнлегендә ачыклык принцибына таянып эш итә.

13. Комиссия түбәндәге карарларны кабул итәргә хокуклы:

1) әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар булмаган очракта оешмалар заявкаларын кире кагу турында;

2) җирле бюджет акчаларын бирү турында, бүлеп бирелә торган акчаларның күләме;

3) җирле бюджет акчаларын бирүдән баш тарту турында;

4) әлеге Тәртиптә күрсәтелмәгән өстәмә (башка) документлар бирү кирәклеге турында.

14. Комиссия секретаре әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән карарларның берсен кабул иткән көннән алып 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Җирле бюджеттан акча бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 7 эш көне эчендә комиссия секретаре тиешле карар проектын эшли. Карар кабул ителгәннән соң район Башкарма комитеты белән мөрәҗәгать итүче арасында килешү Тәртиптә билгеләнгән срокларда төзелә.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль
районы территориясендә уза торган муниципаль
маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга
салына торган тарифлар буенча даими рәвештә
пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга
бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен
каплау максатларында ташучыларга
субсидияләр бирү тәртибенә
1нче кушымта
«10»12.2025 ел № 384

**____________________________ 20__ ел өчен**
**(ай, квартал)**
**Чирмешән муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы__________________________________**
**(автотранспорт предприятиесе)**
**төшеп калучы керемнәрен каплауның исәп-хисап суммалары**

| Маршрут атамасы | Хисап чорында ташылган пассажирлар саны, кеше (торак пунктлар буенча) | Икътисадый нигезләнгән тариф, сум. | Пассажирлар йөртүдән алынган керемнәр, сум. | | Социаль йөрү билеты буенча йөргән өчен дә компенсация суммасы, сум. | Кайтарылырга тиешле төшеп калучы керемнәрне каплау суммасы, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бер тапкыр бирелә торган билетлар, сум. | Айлык юл йөрү билетлары (социаль билетларны да кертеп, сум.) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | |

Оешма җитәкчесе
(вәкаләтле зат) _________________ ________________ _____________
(вазыйфа) (имза) (имзаны расшифровкалау)

Башкаручы _______________ ____________________ ________________________
(вазыйфа) (имза) (имзаны расшифровкалау)